**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

# БОЕРЫК

26.10.2015 Казан шәһәре № 669

**Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында**

**боерам:**

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең теркәлгән тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үземдә калдырам.

Министр В.А.Леонов

Боерык проектына тәңгәлләштерү бите

**Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау**

________26.10.2015____________ № ________669___________

Министрның беренче урынбасары Х.Х.Шәйхетдинов

Министр урынбасары Р.М.Гарифуллин

Министр урынбасары

А.М.Мингулов

Юридик эш секторы мөдире О.Б.Вощакина

Редактор-корректор А.И.Шәйхетдинова

ТР Яшьләр эшләре һәм спорт
министрлыгының
2015 елның 26 октябре
669 № лы боерыгы тарафыннан
расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАРЫНА ҺӘМ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫНА КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗА ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе (алга таба – Тәртип) 2009 елның 17 июлендә чыккан 172-ФЗ номерлы «Норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертиза турында» федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендә 96 нчы номерле карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Методикасы (алга таба – Методика), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендә чыгарылган 883 номерлы «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» карарына туры китереп төзелгән һәм, Министрлык эшләгән норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына бәйсез коррупциягә каршы экспертизаны да кертеп, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) эшләгән норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү процедурасын билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза Министрлыкның җентекләп тикшерелә торган норматив хокукый актлары проектларына (алга таба – норматив хокукый актлар проектлары) хокукый экспертиза үткәргәндә һәм Министрлыкның кабул ителгән норматив хокукый актларын мониторинглау вакытында уздырыла.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты булып норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлары проектларында коррупциоген факторларны ачыклау һәм шуннан соң бетерү тора.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза үз көчен югалткан яисә гамәлдән чыгарылган норматив хокукый актларга карата үткәрелми.

## 2. НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ҺӘМ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫНА КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗА ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Коррупциягә каршы экспертиза Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендә 96 нчы номерле карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Методикасына (алга таба – Методика) туры китереп уздырыла.

2.2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министры (алга таба – министр) Министрлыкта коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затны билгели (алга таба – вазыйфаи зат). Күрсәтелгән вазыйфаи зат шулай ук Министрлыкта коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу Журналын (алга таба – Журнал) алып бару өчен дә җаваплы. (1 нче кушымта).

2.3. Норматив хокукый актны, норматив хокукый акт проектын эшләүче структур бүлекчә (алга таба – эшләүче) норматив хокукый акт проектын вазыйфаи затка коррупциягә каршы экспертизага җибәрә, бу Журналда аның кергән көнендә үк чагыла.

Вазыйфаи зат тарафыннан аларны кулллануның мониторингын үткәрү вакытында норматив хокукый актларда коррупциоген факторлар ачыкланганда, норматив хокукый актлар Журналда коррупциоген факторлар ачыкланган көндә теркәлә.

Эшләүче тарафыннан норматив хокукый актларда аларны куллануның мониторингын үткәрү вакытында коррупциоген факторлар ачыкланган очракта, эшләүче норматив хокукый актны вазыйфаи затка коррупциягә каршы экспертизага җибәрә, бу Журналда шул ук көндә теркәлә.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза норматив хокукый акт һәм норматив хокукый акт проектын Журналда теркәгән көннән башлап җиде көн вакыт эчендә үткәрелә.

2.5. Норматив хокукый актка һәм норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча вазыйфаи зат тарафыннан бәяләмә төзелә һәм имзалана.

Коррупциоген фактлорлар барлыгы турында Бәяләмәдә (2 нче кушымта), Методикага туры китереп, коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциоген факторлар чагылыш таба һәм аларны юкка чыгару алымнары тәкъдим ителә.

Норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциоген факторлар булмаган очракта, коррупциоген факторлар булмавы турында бәяләмә (3 нче кушымта) төзелә һәм эшләүчегә җибәрелә.

2.6. Әгәр экспертизага җибәрелгән норматив хокукый актта коррупциоген факторлар булмаса, эшләүче, коррупциоген факторлар булмавы турында бәяләмәне алгач, структура бүлекчәләренең кызыксынган җитәкчеләре визалары белән норматив хокукый акт проектын министрга имзага юллый.

2.7. Әгәр норматив хокукый актта коррупциоген факторлар булуы ачыкланса, вазыйфаи зат коррупциоген факторлар ачыклану моментыннан бер эш көне

дәвамында коррупциоген факторлар булуы турында бәяләмәне эшләүчегә җибәрә.

Эшләүче, бәяләмәне алгач, министр белән килешеп, аңа үзгәрешләр кертү кирәклеге яки аның көчен югалтуы турында карар кабул итә һәм өч көн эчендә ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү максатыннан норматив хокукый акт проектына үзгәрешләр кертү яисә норматив хокукый актны үз көчен югалткан дип санау турында проект әзерли һәм коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен вазыйфаи затка җибәрә.

2.8. Әгәр экспертизага җибәрелгән норматив хокукый акт проектында коррупциоген факторлар ачыкланса, эшләүче, коррупциоген факторлар булуы турында бәяләмәне алгач, өч көн эчендә барлык кимчелекләрне бетерергә һәм яңадан коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен эшләп бетерелгән норматив хокукый акт проектын вазыйфаи затка җибәрергә тиеш.

2.9. Норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы икенче кат үткәрелә торган экспертизасы өч көн эчендә уздырыла.

2.10. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Журналда чагылыш таба.

2.11. Министрның норматив хокукый актны, норматив хокукый акт проектын коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә хакы бар.

## 3.НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАРГА ҺӘМ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫНА КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ БӘЙСЕЗ ЭКСПЕРТИЗА ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

3.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып Министрлыкның рәсми рәвештә дөнья күргән норматив хокукый актлары һәм интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (http://mdms.tatarstan.ru/) (алга таба – рәсми сайт) урнаштырылган Министрлык әзерли торган норматив хокукый актлар проектлары санала.

3.2. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт сере булып саналган яисә конфиденциаль характердагы мәгълүматлар булган норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларына карата үткәрелми.

3.3. Норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен эшләүче аны министр боерыгы белән билгеләнгән норматив хокукый акт проектларын урнаштыру өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрү көненә туры килүче эш көнендә җибәрә.

3.4. Норматив хокукый акт проектын алу көненә туры килгән эш көне дәвамында җаваплы зат аны рәсми сайтта урнаштыра.

3.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен норматив хокукый актлар проектларын урнаштырганда җаваплы зат эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен министрлыкның адресын (шул исәптән Министрлыкның электрон почта адресын да), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр кабул итүнең башлану һәм тәмамлану даталарын күрсәтә.

3.6. Норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез

экспертиза үткәрү вакыты аларны рәсми сайтта урнаштырган көннән биш эш көненнән дә артмый.

3.7. Норматив хокукый акт һәм норматив хокукый акт проектының коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча Министрлыкка кергән бәяләмә (алга таба – Бәяләмә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында теркәлә һәм коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен эшләүчегә җибәрелә.

3.8. Бәяләмә тәкъдим характерында һәм Министрлык тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш. Эшләүче кергән бәяләмәне карый һәманы алганнан соң 15 көн эчендә коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүче юридик яки физик затка, бәяләмәдә ачыкланган коррупциоген факторларны юк итү ысуллары турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш, дәлилләнгән җавап җибәрә.

3.9. Норматив хокукый акт, норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакытында ачыкланган коррупциоген факторлар Тәртипнең 3.8 пунктында билгеләнгән вакыт эчендә актны эшләүче тарафыннан юкка чыгарыла.

3.10. Бәяләмәдә күрсәтелгән кисәтүләрне юкка чыгарганнан һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, эшләүче норматив хокукый акт проектын, коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча кергән бәяләмәләрне кушып, кабаттан коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен вазыйфаи затка тапшыра. Коррупциягә каршы икенче кат экспертиза өч көн вакыт эчендә үткәрелә.

3.11. Әгәр норматив хокукый актта коррупциоген факторлар ачыкланса, эшләүче бәяләмәне Министрлыкта теркәгән көннән соң өч көн эчендә норматив хокукый актка үзгәрешләр кертү буенча яисә аны көчен югалткан дип санау турында чаралар күрә.

3.12. Эшләүче норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциоген факторлар булуын күрсәтеп торучы коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта закон белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән норматив хокукый актларны, норматив хокукый актлар проектларын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең килешмәвен нигезләгән аңлатма язуын коррупциягә каршы экспертизага Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрә.

3.13. Эшләүче ул эшләгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы законнар чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Җыенының Дәүләт Думасына кертелә торган федераль законнар проектларында, Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциоген факторлар булуы турында коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта әлеге норматив хокукый актлар проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга кертә.

ТР Яшьләр эшләре һәм
спорт министрлыгының
2015 елның ________ __ номерлы
боерыгы белән расланган
ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының
норматив хокукый актлар һәм
норматив хокукый актлар
проектларына коррупциягә каршы
экспертиза үткәрү тәртибенә
1 нче кушымта

КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗАГА КЕРТЕЛГӘН
НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ҺӘМ
НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫН
ИСӘПКӘ АЛУ ЖУРНАЛЫ

| N | Актның (акт проекты) экспертизага керү датасы | Актны (акт проекты) эшләүче структура бүлекчәсе атамасы | Актның (акт проекты) атамасы | Экспертиза үткәрү вакыты | Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе | Бәяләмә бирү датасы |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| | 1 | 2 | 3 | 5 | 6 | 7 |

ТР Яшьләр эшләре һәм
спорт министрлыгының
2015 елның ________ __ номерлы
боерыгы белән расланган
ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының
норматив хокукый актлар һәм
норматив хокукый актлар
проектларына коррупциягә каршы
экспертиза үткәрү тәртибенә
2 нче кушымта

## КОРРУПЦИОГЕН ФАКТОРЛАР БУЛУ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘ

________________________________________________________________

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проекты атамасы)

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы тарафыннан, 2009 елның 17 июлендә чыккан 172-ФЗ номерлы «Норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендә кул куелган 96нчы номерлы «Норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында» карары белән расланган Норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасына туры китереп, аларда коррупциоген факторлар булуын ачыклау һәм аннан соң аларны юкка чыгару максатында

________________________________________________________________

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проект атамасы)
коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде.
Тәкъдим ителгән

________________________________________________________________

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проект атамасы)

________________________________________________________________

(коррупциоген факторларның төрләре күрсәтелә)
коррупциоген факторлар ачыкланды.
Ачыкланган коррупциоген факторларны юкка чыгару максатында ________

________________________________________________________________

(коррупциоген факторларны бетерү ысулы күрсәтелә)
тәкъдим ителә.

__________________ __________ ______________________________ __________
(вазыйфа атамасы) (имза) (инициаллар, фамилия) (дата)

ТР Яшьләр эшләре һәм
спорт министрлыгының
2015 елның ________ __ номерлы
боерыгы белән расланган
ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының
норматив хокукый актлар һәм
норматив хокукый актлар
проектларына коррупциягә каршы
экспертиза үткәрү тәртибенә
3 нче кушымта

КОРРУПЦИОГЕН ФАКТОРЛАР БУЛМАВЫ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘ

___________________________________________________________

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проекты атамасы)

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы тарафыннан, 2009 елның 17 июлендә чыккан 172-ФЗ номерлы «Норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендә кул куелган 96нчы номерлы «Норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында» карары белән расланган Норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасына туры китереп, аларда коррупциоген факторлар булуын ачыклау һәм аннан соң аларны юкка чыгару максатында

___________________________________________________________

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проект атамасы)
коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде.
Тәкъдим ителгән

___________________________________________________________

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проекты атамасы)
коррупциоген факторлар ачыкланмады.

___________________ __________ ___________________________ __________

(вазыйфа атамасы) (имза) (инициаллар, фамилия) (дата)